Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы  башкарма комитеты мәгариф идарәсенең    ана теле һәм әдәбияты укытучыларының Бөтенроссия “Туган тел” мастер- класс бәйгесенә Шәмәрдән лицееның татар теле һәм әдәбияты укытучысы Минһаҗева Нурсия Фоат кызын  тәкъдир итү

**бәяләмәсе.**

Нурсия Фоатовна югары белемле, II квалификацион категорияле, югары дәрәҗәдәге профессиональлеккә ия татар теле һәм әдәбияты укытучысы, 14 ел педагогик стажы бар.

Шушы вакыт эчендә ул үзен балаларны, эшен яратучы оста педагог итеп танытты. Аның дәресләре укучыларда зур кызыксыну уята, чөнки Нурсия Фоат кызы дәресләргә, бай материал туплап, зур хәзерлек белән керә. Укытучы үз-үзен тотышы, эмоциональ матур сөйләме белән укучыларда туган җиргә, туган телгә мәхәббәт, ата-анага, өлкәннәргә карата шәфкатьлелек хисләре тәрбияли. Ул укучыларның мөстәкыйль рәвештә фикерләү сәләтен үстерүгә, грамоталы язуларына һәм сәнгатьле укуларына нык игътибар итә.

Нурсия Фоатовна  татар теле һәм әдәбияты кабинетын заман таләбенә туры килерлек итеп зәвык белән җиһазлады һәм үзенең иҗат лабораториясен туплады. Кабинетның китапханәсе бай. Анда ул һәр язучыга, тел белеме бүлекләренә йөзгә якын папка, индивидуаль карточкалар, тестлар, интеллектуаль сораулар, сюжетлы рәсемнәр, таблицалар, плакатлар, портретлар, методик әдәбият, фонохрестоматияләр, презентацияләр,  ДЙАга әзерләнү өчен методик кулланмалар булдырды.

Нурсия Фоатовна ныклы белем биреп кенә калмыйча,  алган белемнәрен тормышта куллана, логик фикер йөртеп, фикерен дәлилләп аңлата белергә, телдән оста файдаланырга һәм төрле тәрбия бирергә  тырыша. Белем һәм тәрбия бирү  формаларын, чараларын һәм ысулларын дөрес  сайлый, инновацион  технологияләрне  яки аларның элементларын дәрес этапларында мөстәкыйль рәвештә  куллана, сынап  карый һәм  уңышлы гамәлгә ашыра. Шуларның берсе профессор Ә. Рәхимовның “Иҗади үсеш” технологиясе. Әлеге технология һәр баланың да үсешен тәэмин итү юнәлешендә эшләргә мөмкинлек тудыра.

Лицейда бик күп башка милләт балалары да белем ала. Нурсия Фоатовна чит телле балаларда да татар телен өйрәнүгә кызыксыну уяту максатыннан үз методларын, алымнарын һәм чараларын булдырды, татар телен кызыксынып өйрәнүгә шартлар тудырды.

Ул "Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә иҗади үсеш технологиясе ысулларын кулланып укучыларга белем һәм тәрбия бирү" дигән методик тема өстендә эшли һәм бу тема буенча аның гомумиләштерелгән эш тәҗрибәсе һәм билгеле бер уңышлары да бар. 2014  елда район олимпиадасында аның 7 нчы класс укучысы Куклина Алена татар татар теленнән район олимпиадасында 1 нче урын, 8 класс укучысы Смирнова Александра 3 нче урын  алды. “ТАТАРТЕЛЕ. ИНФО” порталында үткәрелгән олимпиадада Минһаҗева Сөмбел җиңүче дипломына ия булды.

Нурсия Фоатовна укучыларның иҗади сәләтләрен үстерүгә, фәнни- эзләнү эшләре белән шөгыльләнүләренә дә зур игътибар бирә. Ул үз фәне буенча сәләтле балалар белән аерым план нигезендә эш алып бара. Хезмәтенең

нәтиҗәсе буларак, аның укучылары иҗади бәйгеләрдә, фәнни-гамәли конференцияләрдә актив катнашалар һәм уңышларга да ирешәләр. Мәсәлән, 2011-2012 нче уку елында республика күләмендә үткәрелгән Ә. Кәримуллин исемендәге фәнни- гамәли конференциядә Рәхимҗанова Эльмира I призлы урын, Яшел Үзән шәһәрендә үткән I республикакүләм Тукай укуларында Ситдикова Лилия грамота, Р.И. Утәмешов исемендәге "Моё Я в Большой науке" республика күләмендәге конференциядә Рәхимҗанова Эльмира III урынны яуладылар, III Бөтенроссия "Татар лингвокультурологиясе: проблемалар һәм перспективалар" конференциясендә Хафизова Зөлфия уңышлы чыгыш ясады, аның эше җыентыкка кертелде. "Ил тарихында гаиләм тарихы" республикакүләм иншалар бәйгесендә Хафизова Зөлфия III урынга лаек булды. 2014-2015 нче уку елында Ибраһим Хәлфин исемендәге X Республика фәнни-эзләнү конференциясендә Гараева Эльвина II урын алуга иреште.

2014-2015 нче уку елында районда татар теле һәм әдәбияты укытучыларының VI Бөтенроссия съезды узды. Нурсия Фоатовна коллегалары белән бергә кунакларга җыен бәйрәме күренешен тәкъдим итте, эш тәҗрибәләре белән уртаклашты. Аларның эшчәнлеге кунаклар тарафыннан югары бәяләнде.

Укытучы көндәшлеккә сәләтле укучы тәрбияләү өчен заман белән бергә атлау кирәк икәнлекне аңлап, укучыларны кызыксындырырлык яңа технологияләр, эшлекле һәм рольле, имитацион уеннар кулланып, укучыларның оештыру сәләтен, икътисади фикерләү сәләтен үстерү өстендә эшли. Һәрчак яңалыкка омтыла, һөнәри осталыгын арттыра, башкалар тәҗрибәсен өйрәнә, үзенең эш тәҗрибәсе белән уртаклаша. Район методик бәрләшмәсе утырышларында "Әдәбият дәресләрендә экологик тәрбия бирү", "Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә яңа педагогик технологияләр куллану", "Белем дәрәҗәсен күтәрүнең вариатив формалары" кебек темаларга чыгышлар ясады. Ш. Мәрҗәни исемендәге тарих институтында үткән конференциядә "Бөек Ватан сугышы темасына язылган әсәрләр аша патриотик тәрбия бирү" дигән темага чыгыш ясап, үзенең эш тәҗрибәсе белән уртаклашты.

Нурсия Фоатовна сәнгатькә гашыйк шәхес. Район, республика күләмендә үткән төрле кичәләрдә, концертларда актив катнаша. Ул үзенең матур җырлавы, оста алып баручы булуы белән һәркемне сокландыра. Укучыларын да үзе артыннан ияртә. Балалар алдында сәнгать дөньясын ача, дөрес һәм образлы сөйләм теле үрнәкләрен күрсәтә. "Сөйләм теле" түгәрәгендә укучыларның артистлык сәләтен, логик фикерләүләрен үстерү өстендә эшли. Ул әлеге түгәрәккә театр, сәнгать, җыр- бию яратучы балаларны туплады, укучыларның уңышлары да зур. Мәсәлән, "Сәләхият" сәнгатьле сөйләм бәйгесендә Гараева Эльвина пароза номинациясендә I урынга, Шәрипова Айсылу поэзия номинациясендә таныклыкка ия булдылар. Республикакүләм "Дулкыннар" конкурсының район этабында Гараева Эльвина II урынга, Минһаҗева Сөмбел шулай ук II урынга лаек булдылар һәм республикага чакыру алдылар.

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы башкарма комитетының
мәгариф идарәсе начальнигы: И. Ф. Шакиров